УДК 745.51

***Л.М. Шкляева***

# УРТА ИДЕЛ БУЕ ТАТАРЛАРЫ ЙОРТЛАРЫН БИЗӘҮДӘ ТӨРКИ ОРНАМЕНТЛАР

Статья посвящена анализу происхождения некоторых орнаментов традиционной деревянной резьбы татар Среднего Поволжья. Указывая на древнетюркское происхождение солярных орнаментов и звериного стиля в резьбе, автор обращает внимание на повсеместное их использование и после принятия ислама. Выполняя вначале обережную функцию, эти орнаменты затем стали неотъемлемой частью декоративной системы татарского народа.

**Ключевые слова:** татарское декоративно-прикладное искусство, традиционная татарская деревянная резьба, экстерьер традиционного татарского дома, тюркский солярный орнамент, тюркский звериный стиль в искусстве.

Традицион татар сәнгате йортларның тышкы ягын кисеп, уеп-сырлап бизәүдә бай орнаменталь системаны тәшкил итә, алар милли тарихи һәйкәлләрнең образлы чагылышын һәм символларын саклау функциясен үтәүдә семантик әһәмияткә ия. П.М. Дульский [Дульский], Ф.Х. Вәлиев [Валеев, 2002], Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова [Валеев, Валеева-Сулейманова, 1987] һәм башка сәнгать белгечләре XIX гасыр ахыры – XX гасырның соңгы чирегендә Казан губернасында яшәүче татарларның агачтан салынган авыл йортларын декоратив бизәүне тикшереп өйрәнүгә зур игътибар бирәләр. Алар орнаментларның бик борынгы төрки мәдәният үрнәкләренә барып тоташуын билгелиләр. Үзенчәлекле татар йортларының тышкы бизәлешендә гомумтөрки, Урта Азия, сәлҗүк һәм Госман империясе дәверләреннән килгән бизәү орнаментларын күзәтергә була [Халитов, 2013]. Бүгенге татарларның борынгы бабаларында гамәли иҗатның барлыкка килүе ерак гасырлардан – Идел Болгарстаны, Алтын Урда, Казан ханлыгы заманыннан ук килә. Әлеге мәкаләдә XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында Урта Идел буенда яшәгән татарларның барлык субэтник төркемнәре (Казан татарлары, мишәрләр, керәшеннәр) тарафыннан кулланылган йорт фасадларын кисеп, уеп эшләү орнаментлары типологиясе карала.

Татарларның йортларны киселмә орнаментлар белән бизәү сәнгате борынгырак төрки дөнья белән киң бәйләнгән. Күчмә төркиләр Урта Идел буена VII йөздә килеп урнашканнар [Хузин, 2010, с. 114–116], алар инде мең еллык тарихка, шул ук вакытта зур үсеш алган мәдәнияткә, һөнәрчелеккә һәм агач эшкәртүнең сәнгати серләренә ия булалар [Казаков, 2006, с. 629–630]. Яңа урында алар башта җирле фин-угорларның стационар торак йортларын төзү ысулларын үзләштерәләр. Утрак тормышны кабул иткән күчмә халык,

мөгаен, йортларны бизәүдә электәге үзләренә таныш орнаментларны һәм киселмә бизәкләрне дә кулланганнардыр.

Борынгы күчмә төркиләрдә агачны сәнгатьчә эшкәртү осталыгы б.э.к. VIII–VI гасырда ук югары дәрәҗәдә була [Баркова, 2012]. Кисеп эшләнгән бизәкләр көнкүреш һәм табыну эшләнмәләренә төшерелә. Сурәтләр, гадәттә, яхшы таныш хайваннар дөньясы образларын гәүдәләндерә. Татарларның борынгы бабалары кабул иткән җәнлекләр стиле зур киңлекләрдәге Дала территорияләрендә яшәгән халык сәнгатендә шартлы чагылыш тапкан, соңыннан ул татар халык сәнгате осталары тарафыннан йортның тышкы ягына киселмә бизәкләр төшерү сәнгате үзенчәлегенә әверелә һәм орнаменталь бизәлеш элементлары сыйфатында шактый таралу ала. Мәсәлән, татар йортлары фасадын матурлау композициясендә симметрия рәвешендә ике якка урнаштырылган мөгезсыман бөтеркә кулланыла. Бу орнаментның килеп чыгышы иң борынгы төркиләр культурасы белән бәйле: алар ат дирбияләренә аккош, тәкә һ.б. фигуралар төшерә торган булганнар [Степанова, 2010, с. 103–110], моны өченче Пазырык курганы табылдыклары раслый. Тәкә (тәкә мөгезе) борынгы төркиләр һәм аларның дәвамчылары өчен яшәүгә сәләтлелек чыганагын гәүдәләндерә.

Урта Идел буе татарлары йортларының киселмә бизәлешендә тагын бер орнаментның мәгънәви эчтәлеген ачыклау борынгы төркиләрне саклаучы символга барып тоташа [Валеев, 1969, с. 27]. Ул – казлар (пар каз) сурәте [Арсланова, 1989, с. 156–160]. Монысы кимәк ыруглык кабиләләре каберлекләреннән табылган әйберләр белән раслана. Каз образлары болгарларның (VIII–IX гасырлар) металлдан яки балчыктан ясалган сәнгати эшләнмәләрендә дә очрый. Пар каз сурәте бизәкләреннән файдалануның аңлатмасы катлаулы түгел, ул «өлешләрдән бөтен булу»ны гына белдерә. Бу кошны томшыгын тамчы рәвеше белән XIX гасыр ахырында торакларның экстерьерына урнаштырганнар, һәм әле хәзер дә бу форма яшәвен дәвам итә. Йортларны киселмә орнаментлар белән һәм башка орнитоморф мотивлар белән бизәү бүгенге халык сәнгатендә дә кулланыла. Моның сәбәбе, мөгаен, исламга кадәрге төрки ышанулар һәм риваятьләр белән бәйлеләр.

Евразиянең күп кенә төрки-монгол халыкларында аккошка табыну көчле булган [Кукашев, 011, с. 79]. Чыңгыз хан үзе ак кошка табынган [Кукашев, 2011, с. 81]. Алтын Урдада XIV гасырда көзгеләрне кош фигуралары белән бизи торган булганнар [Фонякова, 2010, рис. 74–5]. Аккош образлары Казан татарлары халык сәнгатенең йорт бизәлешләрендә әле хәзер дә кулланыла. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Мамадыш районының Баскан авылында аккошлар гаилә бәхетен гәүдәләндерә [Шкляева, 2015, с. 40]. Осталар кошларны парлап, профильдә бер-берсенә каратып, тәрәзә йөзлегенең өске өлешенә

урнаштыралар. Татар җырларында аккошлар сафлык һәм изгелекне символлаштыралар [Габидуллина, Хабибуллина, 2014, с. 32–35]. Кошларга яки җәнлекләргә табыну төрки мәдәниятнең нигезен тәшкил иткән тәңречелеккә барып тоташа [Гумилев, 1967, с. 76–86]. Төркиләрнең халык сәнгатенә күктәге баш Алла-Тәңре һәм аның хатыны – йорт һәм гаиләне яклаучы (мифологиядә еш кына кош рәвешендә кабул ителә торган) Умай образлары тирән үтеп кергән [Степенова, 2010, с. 286].

Борынгы төркиләрдә Тәңре образы соляр розетка рәвешендәге кояш һәм күк белән ассоциацияләнә. Алтын Урда, Идел Болгарстаны һәйкәлләрендә, борынгы төрки чыгышлы артефактларда соляр розеткалар күп төрле формаларда гәүдәләндерелгән. Мәсәлән, б.э.к. V–IV гасырларда яшәгән осталар тарафыннан иҗат ителеп, Пазырык курганнарында табылган эшләнмәләр арасында сигезнурлы розетка белән бизәлгән агач мендәр булуы мәгълүм. Алтай каберлекләрендә ияр покрышкасы өчен дүрттаҗлы чәчәк формасында эшләнгән тәңкә табыла. Ат дирбияләренең кайбер детальләре очына түгәрәк диск рәвешендәге розеткалар беркетелгән булган. Хуннулар (сөнниләр) дәверендә (б.э.к. I гасырда һәм безнең эраның I гасырында) табут тышына розеткалар төшерелгән булган. VIII–X гасырда салтау (болгар-хәзәр) осталары әйберләрне розетка һәм тукранбаш орнаментлары белән бизи торган булганнар [Фонякова, 2010]. Иртә болгар декоратив-гамәли сәнгатенә салтау-маяк культурасының эстетик йогынтысы [Валеева-Сулейманова, 2006, с. 594] Хәзәр каганлыгыннан Урта Иделгә күчеп килүчеләрнең күплеге белән аңлатыла [Халиков, 1969, с. 74]. Розетка орнаментлары белән бизәү буыннан-буынга күчә барган, йортларны киселмә орнаментлар белән матурлау халык сәнгатенә үтеп кергән. Эре розеткалар һәм аларның сегментларын капкаларга урнаштыру бүгенге татарларның борынгы бабалары күчмә тормыш белән гомер кичергәнлеге турында сөйли. Борынгыда тирмәгә керү-чыгу өчен көйләнгән киез ишекләрне ыруглык тамгалары һәм орнаментлар белән бизәү гадәте күчерелмә торакларның агач ишекләренә дә кисеп-уеп эшләнгән бизәкләр төшерүне дәвам итүгә йогынты ясаган. Татарларда өй ишеге койма артына «яшерелгән» була, шуңа күрә ул капка ачылуга күренеп торырлык итеп бизәлә.

Хәзер татарлар йортның тышкы бизәлешендә тукранбаш орнаментларыннан киң файдаланалар. Моның төп чыганагын салтау-маяк культурасы йогынтысы белән болгарларда киң таралыш алган тукранбаш образы тәшкил итә, ә аның беренчел үрнәге төркиләр исламны кабул иткәнче үк инде табигать көчен символлаштырган лалә чәчәк булган [Фенякова, 2010, с. 69]. Тукранбаш гәүдәләнеше иртә болгар декоратив-гамәли сәнгате әсәрләрендә билгеләп үтелә [Валеев, Валеева-Сулейманова, 1987, с. 30–31; Валеева, 1983]. Бу форма, Пазырык культурасы

дәверендә үк төрки кабиләләр тарафыннан файдаланылганлыктан, болгарларга генетик яктан таныш була (аның башлангычы – поши мөгезләренең стильләштерелгән образыннан гыйбарәт). Күрәсең, нәрсәдәндер саклануга нигезләнгән табигый тойгы нәтиҗәсендә бу форманы үсемлек орнаменты алыштырган.

Йортларны тыштан бизәү тарихының төрки катламы татар декоратив сәнгатенең тотрыклы юнәлеше – үреп эшләнгән бизәкләр төшерү белән бәйле. Борынгы күчмә кабиләләр торакларының агач терәген, ныклык өчен, үрелгән баулар белән чорный торган булганнар. Бу алымны соңрак торакның тышкы күренешендә мәҗбүри элемент буларак кабул иткәннәр һәм ул алардан соңгы буыннар осталары тарафыннан үрмә орнамент рәвешендә файдаланылган [Халитов, 2013, с. 36–40]. Хәзер аны татарлар йортларының тышкы ягын бизүдә кулланалар. Әйтик, Татарстанның Мамадыш районы Баскан авылындагы тәрәзә йөзлекләренең өске өлешендә кисеп эшләнгән кошлар сурәтләрен очратасың. Алар ике детальдән тора, берсе – кошның гәүдә контурын, икенчесе аның каймалап үрелгән койрыгын хәтерләтә.

Шулай итеп, борынгы төрки халыкларның дөньяны кабул итүен чагылдырган орнаменталь сәнгатьне татарларның борынгы бабалары да кабул иткән һәм ул болгарларның, аннан соң татар халкының декоратив системасына үтеп кергән. Авылларда әлегә кадәр торак фасадларын бизәүдә төрки чыгышлы орнаментларга символик мәгънә бирәләр. Йортларны тарихи формалашкан милли рухтагы киселмә бизәкләр белән матурлауда алар янәшәсенә элек-электән төрки саналган элементлар өстәлә килә. Татарларның субэтник төркемнәренең дин белән бәйләнмәгән гомум тарихи үткәне төрки орнаменталь катлам аша чагылыш таба.

**Әдәбият**

*Арсланова Ф.Х.* Образ птицы на головных уборах кимакских женщин // Маргулановские чтения: сб. м-лов конф-ции. Алма-Ата: Б. и., 1989. С. 156–160.

*Баркова Л.Л.* Скотоводы Алтая (Пазырыкская культура) в Скифскую эпоху // Кочевники Евразии на пути к империи: СПб.: Принт, 2012. С. 91–103.

*Валеев Ф.Х.* Орнамент казанских татар. Казань: Таткнигоиздат, 1969. 204 с.

*Валеев Ф.Х.* Татарский народный орнамент. Казань: Таткнигоиздат, 2002. 302 с.

*Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Древнее искусство Татарии. Казань: Таткнигоиздат, 1987. 166 с.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Булгарское искусство // История татар с древнейших времен: в 7-ми т. Казань: Рухил. 2006. Т. 2. С. 594–602.

*Валеева Д.К.* Искусство волжских булгар (X – начало XIII вв.). Казань: Таткнигоиздат, 1983. 132 с: ил.

*Габидуллина Ф.И., Хабибуллина Л.И.* Образ птицы в татарской литературе // Филологические науки. Вопросы теории и практики. № 9.4.1. Тамбов. Грамота, 2014. С. 32–35.

*Гумилев Л.Н.* Древние тюрки. М.: Наука, 1967. 504 с.

*Дульский М.П.* Орнамент казанских татар // из архива П. М. Дульского, папка 2 «А» Рукописи. Искусство Татарстана. Казань. Промыслы. 7 с.

*Казаков Е.П.* О взаимодействии волжских болгар с финно-уграми // История татар с древнейших времен в 7-ми т. Казань: Рухил, 2006. Т. 2. С. 629–630.

*Кукашев Р.Ш.* Лебедь – птица шаманская // Символы тюркской культуры. Ташкент: ART-PRESS, 2011. С. 79–83

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2014. 380 с.

*Полякова Г.Ф.* Изделия из цветных и драгоценных металлов // Город Болгар: ремесло металлургов, кузнецов, литейщиков. Казань, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1996. С. 232–235.

*Степанова Е.В.* Конское снаряжение кочевников Алтая скифского времени (по материалам курганов пазырыкской культуры) // Кочевники на пути к Империи. Из собрания государственного Эрмитажа. Каталог выставки. СПб.: Славия, 2010. С. 103–110.

*Фонякова Н.А.* Прикладное искусство Хазарии второй половины VIII–X вв. по материалам художественной металлообработки. Казань: Институт истории АН РТ. 2010. 168 с.

*Халиков А.Х.* Древняя история Среднего Поволжья. М.: Наука, 1969. 394 с.

*Халитов Н.Х.* Стили и формы средневековой архитектуры Казани: историко-архитектурное исследование. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 351 с.

*Хузин Ф.Ш.* К вопросу о времени возникновения оседлости у волжских булгар // Научный Татарстан. 2010. № 4. С. 114–126.

*Шкляева Л.М.* Образ птицы в декоре экстерьера сельских строений татар Среднего Поволжья рубежа XX–XXI веков (по результатам экспедиции 2013 года в Мамадышский район Республики Татарстан) // Вестник Казанского государственного университета культуры и искусств. 2015. № 2. С. 261–304.

***Шкляева Людмила Михайловна,***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли*
*сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

«Милли-мәдәни мирасыбыз: Кукмара» китабын тәкъдим итү







Шкляева Л.М. Урта Идел буе татарлары йортларын бизәүдә төрки орнаментлар



Тәрәзә йөзлекләрендә мөгезсыман бизәкләр



Алтай. Өченче Пазырык кургany табылдыгы



Кабер ташында мөгезсыман бизәк. Оренбург өлкәсе, Татар Каргалысы

---

Яңа китаплар







